**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5101**
**14.06.2023**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җыелма эвакуация пунктларын булдыру һәм аларның эшен оештыру турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2004 елның 22 июнендәге 303 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эвакуация комиссиясен төзү турында» 2020 елның 24 июлендәге 620 номерлы карары нигезендә, аерым чорда эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү һәм аларны тәэмин итү өчен

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җыелма эвакуация пунктлары (алга таба – ҖЭП) исемлеген, 1 нче кушымтада каралганча;

2) ҖЭП турында нигезләмәне, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә 2023 елның 30 июненә кадәр, ана һәм бала бүлмәләрен кирәкле мөлкәт белән комплектлаштыру өчен, һәр ҖЭПка балалар мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен беркетергә.

3. Тәкъдим итәргә:

1) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенә 2023 елның 10 июленә кадәр, медицина пунктын кирәкле мөлкәт һәм медикаментлар белән комплектлаштыру өчен, һәр ҖЭПка медицина учреждениесен беркетергә;

2) Татарстан Республикасы хәрби комиссариатларына (муниципаль), гражданнарны мобилизацияләүне һәм эвакуацияләүне бер тапкыр үткәрү шартларында мобилизация буенча гражданнарны чакыруны гарантияле үткәрү максатында, мобилизация буенча чакыру өчен командаларга һәм партияләргә теркәлгән (беркетелгән) гражданнарны ачыклау бурычларын үтәү өчен, һәр ҖЭПка вәкаләтле хезмәткәр беркетергә;

3) шәһәр оешмалары җитәкчеләренә – ҖЭП формалаштыручыларга, 2023 елның 10 июленә кадәр:

- формалаштырыла торган ҖЭП администрациясен билгеләүне тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча идарәсе белән берлектә ҖЭП эшен оештыру буенча кирәкле документларны эшләргә;

- шәхси сак предприятиеләре көче белән, предприятие хезмәткәрләреннән ҖЭПны саклауны оештырырга;

- ҖЭПта җәмәгать тәртибен саклау буенча төркемнәр булдырырга.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 14 июнендәге
5101 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
җыелма эвакуация пунктлары
исемлеге

| № т/б | ҖЭП урнаштыру урыны, урнаштыру адресы | ҖЭП формалаштыручы оешма исеме, җитәкчеләрнең телефон номерлары | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1. | АБК-407 Автосборочный тыкрыгы 16 | «КАМАЗ» ААҖ<br>Автомобиль заводы<br>37-10-48, 55-10-98, 37-11-58 | |
| 2. | «56 нчы УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре, Яңа шәһәр,<br>Нариманов урамы, 44 йорт | «56 нчы УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>58-93-95 | |
| 3. | «Батырлык ордены кавалеры Дмитрий Бәдретдинов исемендәге 46 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Чулман проспекты, 56 йорт | АБК-6 «КАМАЗ» ААҖ<br>Кою заводы<br>37-34-05, 37-35-62, 37-35-05 | |
| 4. | АБК-6 Кою заводы<br>Металлургическая урамы 20 | «КАМАЗ» ААҖ<br>Кою заводы<br>37-34-05, 37-35-62, 37-35-05 | |
| 5. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 40 нчы УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Шамил Усманов урамы, 96 йорт | «КАМАЗ» ААҖ<br>Ремонт-инструмент заводы<br>37-21-25, 37-10-83, 37-40-30 | |
| 6. | АБК-211 Тимерчелек заводы<br>Моторная урамы 40 | «КАМАЗ» ААҖ<br>Тимерчелек заводы<br>37-49-23, 37-21-16 | |
| 7. | «Орган залы» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Автозаводский проспекты, 8 | «Орган залы» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе<br>54-09-65 | |
| 8. | «КАМАЗ» мәдәният йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе<br>Мир проспекты, 87/22 йорт | «КАМАЗ» мәдәният йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе<br>54-67-53 | |
| 9. | АБК-306 Двигательләр заводы<br>Моторная урамы 34 | «КАМАЗ» ААҖ<br>Двигательләр заводы<br>37-43-03, 37-43-89 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 31 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре, Мир проспекты, 29 йорт | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 31 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>58-78-20 | |
| 11. | АБК-408 (1) АЗ<br>Автосборочный тыкрыгы 16а | «КАМАЗ» ААҖ<br>Автомобиль заводы<br>37-11-58, 55-10-98 | |
| 12. | «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре, Яңа шәһәр, Школьный бульвары, 2 йорт | «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе<br>38-47-15 | |
| 13. | АБК-107 ПРЗ<br>Автосборочный тыкрыгы, 16а | «КАМАЗ» ААҖ<br>Пресс-рам заводы<br>37-46-23, 37-46-20, 37-24-09 | |
| 14. | «38 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре, Яңа шәһәр, Чулман проспекты, 78 йорт | «КАМАЗ» ААҖ<br>Логистика үзәге<br>37-45-07 | |
| 15. | «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Сөембикә проспекты, 47 йорт | «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ<br>52-42-68 | |
| 16. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 24 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Автозаводский проспекты, 39 йорт | «КАМАЗ - Энерго» ҖЧҖ<br>37-29-74, 37-22-50, 33-94-33 | |
| 17. | «28 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Юные Ленинцы бульвары, 7 йорт | «Электротранспорт» ҖЧҖ<br>46-03-70 | |
| 18. | АБК Автомобиль юллары предприятиесе МУП,<br>Резервный тыкрыгы, 42/4 | АЮП МУП<br>20-36-35 | |
| 19. | «48 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Вахитов проспекты, 3 йорт | «48 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>59-70-45 | |
| 20. | «РИПТиБ» региональ алдынгы технологияләр һәм бизнес институты<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Вахитов проспекты, 2 йорт | «Ремдизель» АҖ<br>55-08-55 | |
| 21. | АБК-7, «Мастер» КИП АҖ «КАМАЗ» ААҖ<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Производственный тыкрыгы 45 | «Мастер» КИП АҖ<br>«КАМАЗ» ААҖ<br>53-45-20 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 22. | АБК Фәнни-техник үзәк<br>Транспортный тыкрыгы, 70 | «КАМАЗ» ААҖ<br>БЗГДР и ДР<br>37-27-71, 37-27-90 | |
| 23. | «КАМАЗжилбыт» ҖЧҖ кунакханә комплексы<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Академик Рубаненко бульвары,<br>4 йорт | «КАМАЗжилбыт» ҖЧҖ<br>кунакханә комплексы<br>39-66-77 | |
| 24. | «Мәктәп туклануы» ҖЧҖ<br>Трубный тыкрыгы, 15<br>53-72-46 | «Мәктәп туклануы» ҖЧҖ<br>Трубный тыкрыгы, 15<br>53-72-46 | |
| 25. | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесенең<br>Яр Чаллы институты<br>«КФУ» уку корпусы<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Мир проспекты, 13а йорт | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү ФДАМУ Яр Чаллы институты<br>39-71-40 | |
| 26. | «27 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Мир проспекты, 94 йорт | «27 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>54-39-37 | |
| 27. | АБК «Челтәр компаниясе» АҖ филиалы – Яр Чаллы электр челтәрләре,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Мәскәү проспекты, 114 йорт | «Челтәр компаниясе» АҖ филиалы – Яр Чаллы электр челтәрләре<br>74-55-02 | |
| 28. | «36 нчы инновацион технологияләр лицее» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Яшьлек проспекты, 5А йорт | «36 нчы инновацион технологияләр лицее» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>59-90-79 | |
| 29. | «Яр Чаллы педагогия колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Беляев проспекты, 3 йорт | «ПЖДТ-Сервис» ҖЧҖ<br>39-61-29,<br>33-93-45 | |
| 30. | «23 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Ш. Усманов урамы, 82 йорт | «23 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>54-36-25 | |
| 31. | АБК Яр Чаллы ТЭЦ<br>Тэцовский тыкрыгы, 76 | «Татэнерго» АҖ филиалы<br>Яр Чаллы ТЭЦ<br>21-93-59 | |
| 32. | «14 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Замелекесье поселогы<br>Н. Якупов урамы, 6 йорт | «14 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>23-00-40 | |
| 33. | Яр Чаллы шәһәренең «Дельфин» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль автономияле | «Дельфин» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе<br>70-22-03 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Габдулла Тукай яр буе,<br>12 йорт | | |
| 34. | «Калкан» кадетлар полиция мәктәбе" ДБГББУ<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Жуков урамы, 36 йорт | «Бумажник» ТИ» БҖЧЖ<br>46-25-06 | |
| 35. | «Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Академик Королев урамы, 20 йорт | «Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>34-70-72 | |
| 36. | «25 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Мир проспекты, 54 йорт | «25 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ<br>38-85-79 | |
| 37. | «76 нчы гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Чулман проспекты, 72 йорт | «76 нчы гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>52-42-57 | |
| 38. | «61 нче гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Романтики бульвары, 2 йорт | «61 нче гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>30-55-60 | |
| 39. | «29 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Юные Ленинцы бульвары, 3 йорт | «Челныстройремонт» ИО ҖЧЖ<br>54-19-22 | |
| 40. | «3 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Юность тыкрыгы, 1 йорт | «3 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>70-40-37 | |
| 41. | «9 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре Грин урамы 8/2 | «Агросила молоко» ҖЧҖ филиалы<br>47-28-30 | |
| 42. | 48 нче автобаза, БСИ<br>Мелиораторная урамы 2б | «Трест Камдорстрой» АҖ<br>45-01-55 | |
| 43. | «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Ш. Усманов урамы, 5 йорт | «Строим будущее» ИК ҖЧҖ<br>25-11-25 | |
| 44. | «Чаллы икмәге» акционерлык җәмгыяте,<br>Хлебный тыкрыгы, 39 йорт | «Чаллы икмәге» АҖ<br>39-75-35 | |
| 45. | «7 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, | «7 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Яр Чаллы шәһәре,<br>Комаров урамы, 29 йорт | 46-07-11 | |
| 46. | «Энергетик» мәдәният сарае» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесе,<br>Габдулла Тукай исемендәге яр буе, 31 | «Яр Чаллы сәнгать колледжы» ДАҺББУ<br>71-51-91 | |
| 47. | «5 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Энергетики тыкрыгы, 1 йорт | «Домкор индустрия» ҖЧҖ<br>25-00-99 | |
| 48. | «13 нче балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Касыймов бульвары, 6 йорт | «13 нче балалар сәнгать мәктәбе» МАӨББУ<br>34-20-81 | |
| 49. | «1 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Тинчурин бульвары, 2 йорт | «1 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>71-10-21 | |
| 50. | «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Батенчук урамы, 17 йорт | «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе<br>70-13-37 | |
| 51. | «77 нче гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Шишкинский бульвары, 11 йорт | «77 нче гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>56-87-02 | |
| 52. | «Шатлык» 1 нче балалар бакчасы - баланы үстерү үзәге» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>М. Җәлил проспекты, 31 йорт | «Жилкомсервис» ҖКФ ҖЧҖ<br>70-33-89 | |
| 53. | «Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Казан проспекты, 17 йорт | «Ак Барс Металл» ҖЧҖ<br>91-17-37 | |
| 54. | АБК «Р.О.С.Л.А.» ҖЧҖ, БСИ,<br>Цеховой тыкрыгы, 8 | «Р.О.С.Л.А.» ҖЧҖ<br>92-89-00 | |
| 55. | «Урман иясе» 88 нче балаларның танып белү-сөйләм үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Санчин яр буе, 16 | Яр Чаллы катыргы-кәгазь комбинаты халык предприятиесе ЯАҖ<br>79-19-55 | |
| 56. | Яр Чаллы шәһәренең «64 нче | Яр Чаллы шәһәренең | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | прогимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>М. Җәлил проспекты, 37 | «64 нче прогимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>70-13-28 | |
| 57. | «10 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Гидростроители урамы, 5 йорт | «10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ<br>70-01-00 | |
| 58. | «11 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Ш. Усманов урамы, 10 | «Электротехник» ИК ҖЧҖ<br>45-03-63 | |
| 59. | «Гали Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Мәскәү проспекты, 100 йорт | «Г. Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат» МАГББУ<br>58-51-31 | |
| 60. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 34 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Ш. Усманов урамы, 110 йорт | «КамстройСервис» ИК ҖЧҖ, Автозаводский проспекты, 36<br>54-44-22 | |
| 61. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 24 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Сөембикә проспекты, 103 йорт | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 37 нче УГББМ» МБГББУ<br>42-56-25 | |
| 62. | АБК «Домкор Строй» ҖЧҖ<br>Иске Сарман, 21 | «Домкор Строй» ҖЧҖ<br>46-50-50 | |
| 63. | «17 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Р. Беляев проспекты, 26 йорт | «17 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>39-42-35 | |
| 64. | «4 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Һ. Такташ урамы, 35 йорт | «4 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>46-55-02 | |
| 65. | АБК «РБР-16» ҖЧҖ,<br>Магистральная урамы; 12 | «РБР-16» ҖЧҖ<br>70-65-05 | |
| 66. | «8 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Һади Такташ урамы, 36/7 | «8 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>46-66-32 | |
| 67. | «А.С. Пушкин исемендәге 78 нче лицей» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе, | «Паритет» ИК ҖЧҖ<br>92-60-65 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Яр Чаллы шәһәре,<br>Чулман проспекты, 62 йорт | | |
| 68. | «60 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Беляев проспекты, 60 | «60 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>35-13-93 | |
| 69. | «22 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Солнечный бульвары, 2 йорт | «Ремжилстрой» ИК ҖЧҖ<br>54-94-42 | |
| 70. | «6 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Һ. Такташ урамы, 27 йорт | «6 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>46-88-76 | |
| 71. | «Советлар Союзы Герое Никита Кайманов исемендәге кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>40 лет Победы урамы, 29 йорт | «Советлар Союзы Герое Никита Кайманов исемендәге кадетлар мәктәбе» ДБГББУ<br>58-31-10 | |
| 72. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 50 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Ш.Усманов урамы, 19 йорт | «Мәхәллә» ИК ҖЧҖ<br>34-59-23 | |
| 73. | «Яр Чаллы технология техникумы» ДАҺББУ, Яр Чаллы шәһәре,<br>Мәскәү проспекты, 95 | «Яр Чаллы технология техникумы» ДАҺББУ<br>58-70-79 | |
| 74. | «57 нче гимназия» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Дружба Народов проспекты, 9А | «Булгарпиво» ААҖ<br>30-54-00 | |
| 75. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 44 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Бумажники бульвары, 3 йорт | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 44 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>46-15-13 | |
| 76. | «20 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Сәйдәшев бульвары, 10 йорт | «20 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>71-23-65 | |
| 77. | Яр Чаллы шәһәренең «21 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Железнодорожники урамы, 65 йорт | «21 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>46-66-31 | |
| 78. | «Сатурн» ҖЧҖ<br>Татарстан Республикасы,<br>Яр Чаллы шәһәре, | Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты ЮББ ФДБМУ, квалификация күтәрү | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Профильная урамы, 90/1 йорт | факультеты,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Батенчук урамы, 21<br>92-78-80 | |
| 79. | «Веста» УГББМ» шәхси белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Яр Чаллы проспекты, 53 йорт | «Веста» УГББМ» ШББУ<br>34-07-53 | |
| 80. | «51 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Автомобилестроители бульвары, 9 йорт | «51 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>59-27-60 | |
| 81. | «12 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Корчагин бульвары, 2 йорт | «12 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>71-03-78 | |
| 82. | «52 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Автомобилестроители бульвары, 5 йорт | «52 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>59-36-88 | |
| 83. | «58 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Кол Гали бульвары, 22 йорт | «58 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>34-04-32 | |
| 84. | «49 нчы кадетлар мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Чулман проспекты, 136 | «49 нчы кадетлар мәктәбе» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе<br>42-50-02 | |
| 85. | «Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>М. Җәлил проспекты, 10 йорт | «Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш колледжы» ДАҺББУ<br>58-93-93 | |
| 86. | «Л.Б. Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>М. Җәлил проспекты, 14 йорт | «Л.Б. Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» ДАҺББУ<br>70-77-29 | |
| 87. | «Кама техник-икътисад колледжы» шәхси һөнәри белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Мир проспекты, 76 йорт | «Шәһәр яшелләндерү хуҗалыгы» ААҖ<br>92-88-01 | |
| 88. | «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» ДАСХКУ<br>Яр Чаллы шәһәре, | «Доверие» ХСХККҮ»<br>ДАСХКУ<br>70-75-95 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Александр Грин урамы, 9 йорт | | |
| 89. | «Л.Б. Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе «КДАМТ»<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>М. Җәлил проспекты, 6 | «Л.Б. Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» ДАҺББУ<br>70-77-29 | |
| 90. | «Яр Чаллы политехника колледжы» дәүләт автономияле һөнәри белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Беляев проспекты, 5 йорт | «Яр Чаллы политехника колледжы» ДАҺББУ<br>58-51-18 | |
| 91. | «26 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Главмосстроевцы бульвары, 2 йорт | «26 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>38-45-90 | |
| 92. | «Чаллы» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре<br>Сөембикә проспекты, 44 йорт | «Чаллы» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе<br>57-34-80 | |
| 93. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 19 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Шишкинский бульвары, 9 йорт | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 19 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>54-26-11 | |
| 94. | «79 нчы лицей-интернат» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Татарстан урамы, 27 йорт | «9 нчы лицей-интернат» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>58-83-02 | |
| 95. | «Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов исемендәге 82 нче кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Чулман проспекты, 38 | «Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов исемендәге 82 нче кадетлар мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>30-55-60 | |
| 96. | «54 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Касыймов бульвары, 6 йорт | «54 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>30-55-60 | |
| 97. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 18 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Строители бульвары, 1 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 18 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>38-76-41 | |
| 98. | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 45 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Чулман проспекты, 34 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 45 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>58-86-04 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 99. | «53 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Касыймов бульвары, 23 | «53 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе 51-13-74 | |
| 100 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 32 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Яр Чаллы шәһәре, Цветочный бульвары, 15 | «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 32нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе 54-28-04 | |
| 101. | «33 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Яр Чаллы шәһәре, Татарстан урамы, 14 йорт | «33 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе 54-95-03 | |
| 102. | «15 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе Яр Чаллы шәһәре, Шишкинский бульвары, 26 йорт | «15 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе 54-42-46 | |
| 103. | «55 нче УГББМ» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе Яр Чаллы шәһәре, Ш. Усманов урамы, 128 А йорт | «Чаллы су каналы» ҖЧҖ 54-44-50 | |
| 104. | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесенең Яр Чаллы институты Яр Чаллы шәһәре, Мир проспекты, 68/19 йорт | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү ФДАМУ Яр Чаллы институты 39-59-72 | |
| 105. | «30 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Яр Чаллы шәһәре, Илдар Маннанов урамы, 12 йорт | «30 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе 49-04-15 | |
| 106. | «41 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Яр Чаллы шәһәре, Илдар Маннанов урамы, 11 йорт | «41 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе 25-30-41 | |
| 107. | «Адымнар-Чаллы гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Яр Чаллы шәһәре, Чулман проспекты, 91 йорт | «Адымнар-Чаллы гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе 47-71-32 | |
| 108. | «42 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Яр Чаллы шәһәре, Г. Кутуй урамы, 7 йорт | «42 нче УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе 91-01-42 | |
| 109. | «62 нче мәгариф үзәге» УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | «62 нче мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Яр Чаллы шәһәре<br>Г. Әпсәләмов урамы, 21В | 23-01-00 | |
| 110. | «39 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе,<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Нур Баян урамы, 10 йорт | «39 нчы УГББМ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br>57-29-98 | |
| 111. | «Яр Чаллы медицина колледжы» ДАҺББУ<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Орловская урамы, 7 йорт | «Яр Чаллы медицина колледжы» ДАҺББУ<br>34-60-00 | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2023 елның 14 июнендәге
5101 номерлы карарына
2 нче кушымта

Җыелма эвакуация пункты турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2004 елның 22 июнендәге 303 номерлы Карары нигезендә җыелма эвакуация пунктлары (алга таба – ҖЭП) эвакуацияләнә торган халыкны җыю һәм исәпкә алу һәм аны оешкан төстә куркынычсыз районнарга озату өчен төзелә. ҖЭП иҗтимагый билгеләнештәге биналарда, транспортка утырту пунктларына якын урында урнаша.

2. ҖЭП шәһәрнең эвакуация комиссиясе, арадаш эвакуация пункты администрациясе, куркынычсыз районнарда урнашкан эвакуация-кабул итү комиссияләре, шулай ук эвакуация чараларын үткәрү өчен транспорт бирә торган оешмалар арасында элемтә белән тәэмин ителә. ҖЭПка эшләмәүче гаилә әгъзалары булган хезмәткәрләрнең оешмалары һәм производствода эшләмәүче башка халык беркетелә һәм алар әлеге җыелма эвакуация пункты аша эвакуацияләнә.

3. ҖЭПка түбәндәгеләр беркетелә:

1) гражданнар оборонасының якындагы саклау корылмалары яки биналарның яшеренү сыйфатында файдаланылырга мөмкин булган подвал бүлмәләре;

2) медицина учреждениеләре (килешү буенча);

3) мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре;

4) транспорт чаралары бирә торган оешмалар (килешү буенча).

4. Халыкны ҖЭПка теркәү бер пунктка 4000-5000 кеше исәбеннән башкарыла. ҖЭПка бирелә торган транспорт чараларының саны теркәлгән халык санына, билгеләнгән срокта халыкны чыгаруны тәэмин итә торган автоколонна тарафыннан гамәлгә ашырыла торган рейслар санына туры китереп билгеләнә. ҖЭП аша эвакуация чаралары производство-территориаль принцип буенча планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла, аның нигезендә эшчеләрне, хезмәткәрләрне һәм аларның эшләмәүче гаилә әгъзаларын таратып урнаштыру һәм эвакуацияләү оешмалар буенча оештырыла һәм үткәрелә, ә калган халыкны эвакуацияләү территориаль принцип буенча, яшәү урыны буенча торак-эксплуатация органнары аша башкарыла. ҖЭПны урнаштыру гражданнар оборонасының гомуми әзерлек чараларын үтәгәндә яки гомуми яки өлешчә эвакуация үткәрү өчен турыдан-туры күрсәтмәләр алганда башкарыла.

5. ҖЭПның эвакуацияләнә торган халыкны үз вакытында җыюны һәм озатуны тәэмин итү эше тәүлек буе оештырыла. ҖЭП администрациясе, базасында ҖЭП урнаштырыла торган оешмаларның, шулай ук аның аша үз кешеләрен эвакуацияләүче оешмаларның хезмәткәрләре арасыннан билгеләнә.

6. ҖЭП башлыгы шәһәрнең эвакуация комиссиясе рәисенә, шулай ук гражданнар оборонасы җитәкчесенә һәм базасында ҖЭП булдырылган оешманың эвакуация комиссиясе рәисенә буйсына. ҖЭП башлыгы, тыныч вакытта алдан ук, Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методика үзәгенең Яр Чаллы шәһәрендәге филиалында әзерлек уза. ҖЭП хезмәткәрләре эш урынында, шулай ук гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләрдә һәм тренировкаларда әзерләнәләр.

7. ҖЭП администрациясе, табигый һәм техноген характердагы зур масштаблы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы янаганда (барлыкка килгәндә), үзенең функциональ вазыйфаларын үтәүгә җәлеп ителергә мөмкин. ҖЭПның эшкә әзерлеге, ҖЭП составына керүче хезмәткәрләрне әзерләү, аны кирәкле матди-техник мөлкәт белән җиһазландыру өчен җаваплылык ҖЭП эшен формалаштыра һәм тәэмин итә торган оешмаларның җитәкчеләренә йөкләнә.

8. ҖЭПның төп бурычлары булып тора:

1) шәһәрнең эвакуация комиссиясе, ҖЭПка теркәлгән оешмалар, ҖЭПка транспорт бирү өчен җаваплы транспорт оешмалары, арадаш эвакуация пунктлары һәм ҖЭП аша халыкны эвакуацияли торган муниципаль районнарның кабул итүче эвакуация комиссияләре белән үзара эшчәнлек;

2) ҖЭПка теркәлгән оешмаларга һәм халыкка ҖЭПка килү вакыты турында үз вакытында хәбәр итү;

3) эвакуацияләнә торган халыкны (алга таба – эвакуацияләнүче халык) шәһәр чите зонасына озату өчен транспорт чараларының үз вакытында бирелүен контрольдә тоту;

4) барлык төр транспортта озатыла торган эвакуацияләнүче халык исәбен алып баруны;

5) эвакуацияләнүче халыкны транспортка утыртуны һәм эвакуацияләнүче халыкны шәһәр читендәге зонага озатуны оештыру;

6) ҖЭПта булганда авыруларга кирәкле медицина ярдәме күрсәтү;

7) радиация һәм химик күзәтү алып бару;

8) халыкның җәмәгать тәртибен үтәвен оештыру;

9) гражданнар оборонасы сигналлары буенча эвакуацияләнүче халыкның саклану корылмаларында яшеренүен оештыру.

## 2 бүлек. ҖЭП структурасы

9. ҖЭП түбәндәге структурага ия:

| | |
|---|---|
| **Идарә** | |
| ҖЭП башлыгы | - 1 кеше |
| ҖЭП башлыгы урынбасары | - 1 кеше |
| Комендант | - 1 кеше |
| **Хәбәр итү һәм элемтә төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Оператор-телефонист (саны хәбәр ителә торган оешмалар санына бәйле рәвештә) | - 3-6 кеше |
| **Теркәү һәм исәпкә алу төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Төркем башлыгы ярдәмчесе – өлкән хисапчы | - 1 кеше |
| Хисапчылар (саны ҖЭП йөкләнешенә бәйле рәвештә) | - 3-6 кеше |
| **Колонналарны формалаштыру (комплектлаштыру) төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Төркем башлыгы ярдәмчесе | - 1 кеше |
| Формалаштыручы (саны ҖЭП йөкләнешенә бәйле рәвештә) | - 4-8 кеше |
| Һәр ҖЭПта колонналарны формалаштыру (комплектлаштыру) төркеме составына автоколонна башлыклары кертелә. | |
| **Транспорт белән тәэмин итү төркеме** | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Төркем башлыгы ярдәмчесе | - 1-2 кеше |

| | |
|---|---|
| Яшеренү төркеме | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Төркем башлыгы ярдәмчесе | - 1-3 кеше |
| Җәмәгать тәртибен саклау төркеме | |
| Төркем башлыгы | - 1 кеше |
| Патруль (саны ҖЭП йөкләнешенә бәйле рәвештә) | - 1-4 кеше |
| Тәртип саклау посты (ЭЭМ хезмәткәрләре) | - 2 кеше |
| Медицина пункты | |
| Пункт башлыгы – фельдшер | - 1 кеше |
| Шәфкать туташы | - 1 кеше |
| Санитария машинасын йөртүче | - 1 кеше |
| Ана һәм бала бүлмәсе | |
| Бүлмә мөдире | - 1 кеше |
| Тәрбияче | - 1-3 кеше |
| Радиация һәм химик күзәтү посты | |
| Пост башлыгы | - 1 кеше |
| Дозиметрист | - 1 кеше |
| Белешмәләр өстәле | |
| Өстәл башлыгы | - 1 кеше |
| Ярдәмче | - 1 кеше |

ҖЭПта барлыгы 35 – 53 кеше.

10. ҖЭПта, эшләмәүче халыкка индивидуаль саклану чаралары (алга таба – ИСЧ) бирү өчен, 29 кешегә исәпләнгән ИСЧ бирү пункты урнаштырыла.

## 3 бүлек. Җыелма эвакуация пункты эшен оештыру тәртибе

11. Гражданнар оборонасын «Гомуми әзерлек»кә китерү өчен күрсәтмә алганнан соң, территориаль, тармак һәм объектлы эвакуация органнары булдырыла һәм әзерлеккә китерелә. 1-2 сәгать эчендә ҖЭП администрациясен җыю башкарыла. Эвакуация чараларын үткәрүгә күрсәтмә алган вакыттан башлап 3-4 сәгать эчендә, ҖЭП урнаштырыла һәм эшкә әзер була.

12. ҖЭП булдырылганнан соң ҖЭП башлыгы түбәндәгеләрне оештыра:

- штат-вазыйфа исемлеге нигезендә ҖЭПның шәхси составын тикшерү;
- эчке эшләр идарәсе хезмәткәрләренең җәмәгать тәртибен саклау төркеменә килүе;
- балалар гомуми белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренең ана һәм бала бүлмәсенә килүе;
- медицина учреждениесе хезмәткәрләренең ҖЭП медицина пунктына килүе;
- автомобиль колоннасының килүен аныклау;
- ҖЭПка теркәлгән оешмалар җитәкчелеге белән эвакуацияләнергә тиешле халык санын, аны куркынычсыз районнарга озату тәртибен һәм срокларын аныклау;
- ҖЭПка теркәлгән барлык төр транспорт белән эвакуацияләнүче халыкны чыгаруга исәп-хисапларны аныклау;
- эвакуацияләнүче халыкка индивидуаль саклану чараларын бирү буенча чараларны гамәлгә ашыру;
- ҖЭПка килүче эвакуацияләнүче халыкны теркәү һәм исәпкә алу;
- колонналар һәм эвакуация эшелоннары булдыру; эвакуацияләнүче халыкны транспорт чараларына утырту;
- ҖЭПның барлык төркемнәре эшен;
- колонна башлыкларына инструктаж үткәрү;
- ҖЭПта булган вакытта авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү;

- җәмәгать тәртибен саклау һәм гражданнар оборонасы сигналлары буенча эвакуацияләнүче халыкны яшерү;

- эвакуация чаралары тәмамлангач, шәһәр эвакуация комиссиясе күрсәтмәсе буенча халыкны шәһәр читендәге зонага озату турында шәһәр эвакуация комиссиясенә доклад әзерләү;

- ҖЭПның шәхси составын эвакуацияләү.

13. ҖЭП администрациясе, эвакуацияләнә торган халык килгән саен, оешмаларның эвакуация комиссияләре вәкилләре белән берлектә, аны кабул итүне, теркәүне, бүлүне, автомашиналар буенча башлыкларны билгеләүне һәм билгеләнгән вакытта формалаштыручылар ярдәмендә оешмаларның утырту пунктына чыгуын оештыра.

14. ҖЭПка автоколонналар (пунктлар, утырту урыннары) бирү вакыты эвакуация чараларын үткәрүгә күрсәтмә алган вакыттан башлап 4 сәгатьтән дә соңга калмаган вакытка билгеләнгән.

15. Беренче колонналар белән озатыла торган оешмаларга хәбәр итү, оешмалар ҖЭПка 4 сәгатьтән дә соңга калмыйча килерлек итеп үткәрелә. Алга таба, ҖЭПка теркәлгән оешмаларга хәбәр итү чираттагы автомобиль колоннасы китү вакытына кадәр 5-6 сәгать алдан гамәлгә ашырылырга тиеш. Эвакуацияләнүчеләр ҖЭПка колонна киткәнче кимендә 1 сәгать алдан килергә тиеш.

16. Һәр колоннаны озатканнан соң, ҖЭП башлыгы шәһәр эвакуация комиссиясенә кирәкле мәгълүматларны тапшыра.

17. Транспорт бирү тоткарланган очракта, ҖЭП башлыгы шәһәр эвакуация комиссиясенә транспорт тоткарлану сәбәбе турында хәбәр итә, шулай ук ҖЭПта һәм утырту урыннарында кешеләр күп җыелуны булдырмау максатларында, әлеге транспортка беркетелгән оешмаларны кисәтә.

18. ҖЭПта җәмәгать тәртибен тәэмин итүне җәмәгать тәртибен саклау төркеме белән берлектә комендант оештыра.

19. Эвакуация чараларын үткәрү чорында эвакуацияләнүче халыкка медицина ярдәме күрсәтү ҖЭПта, утырту пунктларында, эвакуация маршрутларында, шулай ук шәһәр читендәге зонада төшерү һәм урнаштыру районнарында оештырыла. Әлеге максатлар өчен медицина хезмәткәрләре, гражданнар оборонасы чараларын медицина белән тәэмин итү планы нигезендә, шәһәрнең дәвалау учреждениеләре тарафыннан бирелә. ҖЭПта булдырыла торган медицина пункты составына бер фельдшер һәм 1-2 шәфкать туташы керә. Медпунктның бурычы – ҖЭПта урнашкан халыкка табибка кадәр медицина ярдәме күрсәтү.

20. Эвакуацияләнә торган халыкка гомуми эвакуация исемлекләре төзелә. Эшчеләр һәм хезмәткәрләр гаиләсенең эшләмәүче әгъзалары гаилә башлыгының эш урыны буенча оешмаларда, ялгыз яши торган эшләмәүчеләр – яшәү урыны буенча (торак-эксплуатация органнарында) исемлеккә кертелә.

21. Мәктәп-интернатларда укучылар (яшәп), балалар йортларында тәрбияләнүчеләр, шулай ук картлар йортларында һәм инвалидлар йортларындагы пенсионерлар үз учреждениеләре һәм оешмалары составында эвакуацияләнә.

22. Мобилизация буенча Кораллы Көчләргә чакырыла торган, шулай ук хәрби хезмәт үтүче эшчеләр һәм хезмәткәрләр гаиләсенең эшләмәүче әгъзалары элек гаилә башлыгы эшләгән оешмалар белән бергә эвакуацияләнә.

23. Эвакуация исемлекләре алдан ук 3 нөсхәдә төзелә һәм, эвакуация планнарына периодик рәвештә төзәтмәләр керткәндә, шулай ук гражданнар оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә аныклана.

24. Эвакуация үткәрүгә күрсәтмә алганнан соң исемлекләрнең беренче нөсхәсе оешмада кала; икенчесе ҖЭПка җибәрелә һәм халыкны алып китү (чыгару) тәмамлангач, эвакуация комиссиясенә тапшырыла; өченчесе, теркәлгәннән һәм урнашканнан соң шушы эвакуацияләнүче халыкны кабул итә торган кабул итү эвакуация пункты (КЭП) аша, урнаштыру районында эвакуация кабул итү комиссиясенә җибәрелә.

25. Эвакуация исемлекләре һәм паспортлар эвакуацияләнә торган халыкны исәпкә алу, урнаштыру һәм беренче чиратта яшәешен тәэмин итү өчен төп документлар булып тора.

26. Эвакуацияләнә торган халыкны утырту урынына турыдан-туры килү түбәндәгеләргә рөхсәт ителә:

1) инвалидлар һәм картлар йортларындагы гражданнарга, мәктәп-интернатларда укучыларга, балалар йортларында тәрбияләнүчеләргә, хезмәт күрсәтүче персоналы һәм аларның гаилә әгъзалары белән махсус балалар учреждениеләренә;

2) югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентларына, профессор-укытучылар һәм аларга хезмәт күрсәтүче персонал һәм аларның гаилә әгъзалары белән һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларга.

27. Әлеге оешмаларның эвакуация комиссияләре вәкилләре ҖЭПка килергә, үз оешмаларын теркәргә, эвакуацияләнүчеләргә кирәкле документларны тапшырырга, автоколонналар буенча бүленеш мәгълүматларын алырга һәм шуннан соң гына кешеләрне утыртырга алып барырга тиеш.

28. Эвакуация чаралаы үткәрү чорында шәһәр транспортының тәүлек буе эшләве оештырыла.

29. ҖЭП эшен оештыру өчен төп озату документы булып оешма җитәкчесенең ҖЭП администрациясен билгеләү турында боерыгы һәм әлеге ҖЭП өчен халыкны һәм матди кыйммәтләрне эвакуацияләү планыннан өземтә тора.

## 4 бүлек. Эшләмәүче халыкны эвакуацияләүне оештыру үзенчәлекләре

30. Эшләмәүче халыкны һәм ялгыз пенсионерларны эвакуацияләү территориаль принцип буенча, ягъни яшәү урыны буенча башкарыла һәм идарәче компанияләргә йөкләнә. Аларда исәпкә алу оештырыла, эвакуация планына төзәтмәләр керткәндә, шулай ук гражданнар оборонасын сугыш вакытына күчергәндә һәм эвакуацияләү өчен күрсәтмә алганда елына кимендә ике тапкыр төгәлләштерелә торган исемлекләр төзелә.

31. Эшләмәүче халыкны гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә укыту йорт идарәләре каршында төзелгән укыту-консультация пунктларында (УКП) оештырыла. Дәресләргә йөрү, адреслар һәм телефоннар күрсәтелеп, эшләмәүче халыкның дәресләрен һәм консультацияләрен исәпкә алу журналларында теркәлә.

32. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, ялгыз пенсионерларны һәм эшләмәүче халыкны эвакуацияләгән очракка, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча идарәсе белән килештерелә торган шәһәрнең торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиеләренә хәбәр итү схемасын эшли.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева